| | | |
|---|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.12.2014 Казан ш. № 5-38/тэ

***“ТГК-16” ААҖнең билгеләнгән электр энергиясе генерацияләү куәте 25 мегаватт һәм күбрәк булган җылылык энергиясе чыганаклары электр һәм җылылык энергияләрен комбинацияле чыгару режимында җылылык энергиясе чыганаклары коллекторларында җитештергән җылылык энергиясенә 2015 елга тарифлар билгеләү турында***

“Җылылык белән тәэмин итү турындагы” 27.07.2010 ел № 190-ФЗ федераль законына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәяләр билгеләнү турындагы” 22.10.2010 ел № 1075 карарына, Тарифлар буенча федераль службаның “Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә көйләүле бәяләрне (тарифларны) исәпләү буенча методик күрсәтмәләрне раслау турындагы” 13.06.2013 ел № 760-э һәм “Билгеләнгән электр энергиясе генерацияләү куәте 25 мегаватт һәм күбрәк булган җылылык энергиясе чыганаклары электр һәм җылылык энергияләрен комбинацияле чыгару режимында җитештергән җылылык энергиясенә (егәрлеккә) 2015 елга соң чик минималь һәм максималь тарифлар билгеләү турындагы” 10.10.2014 ел № 226-э/2 боерыкларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15.06.2010 № 468 карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында кагыйдәләренә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Билгеләнгән электр энергиясе генерацияләү куәте 25 мегаватт һәм күбрәк булган “ТГК-16” ЯАҖнең җылылык энергиясе чыганаклары электр һәм җылылык энергияләрен комбинацияле чыгару режимында җылылык энергиясе чыганаклары коллекторларында җитештергән җылылык энергиясенә тарифларны шушы карарның кушымтасына ярашлы рәвештә билгеләргә.

2. Шушы карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2015 елның 1 гыйнвареннан 2015 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Шушы карар аны рәсми игълан иткән көннән ун көн үткәч үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тарифларбуенча
Дәүләт комитеты Рәисе М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
12.12.2014 № 5-38/тэ
карарына кушымта

## “ТГК-16” ААҖнең билгеләнгән электр энергиясе генерацияләү куәте 25 мегаватт һәм күбрәк булган җылылык энергиясе чыганаклары электр һәм җылылык энергияләрен комбинацияле чыгару режимында җылылык энергиясе чыганаклары коллекторларында җитештергән җылылык энергиясенә 2015 елга календарь буенча бүленгән тарифлар

| Т. № | Көйләнүче оешманың атамасы | Тариф төре | Ел | Су | Алынган парның басымы | | | | Үткен һәм редукция-ләнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 1,2-2,5 кг/см$^2$ | 2,5-7,0 кг/см$^2$ | 7,0-13,0 кг/см$^2$ | > 13,0 кг/см$^2$ | |
| 1 | “ТГК-16” ААҖ» | | | | | | | | |
| 1.1 | Чыганак – “ТГК-16” филиалы – Казан ТЭЦы-3 | Бер ставкалы тариф, сум/Гкал | 01.01.2015-30.06.2015 | 453,76 | | | 574,96 | 640,33 | 702,29 |
| | | | 01.07.2015-31.12.2015 | 470,81 | | | 602,60 | 672,76 | 738,54 |
| 1.2 | Чыганак – “ТГК-16” филиалы – Түбән Кама ТЭЦы (ПТК-1) | Бер ставкалы тариф, сум/Гкал | 01.01.2015-30.06.2015 | 452,31 | | | | 604,91 | 656,20 |
| | | | 01.07.2015-31.12.2015 | 472,59 | | | | 641,46 | 696,21 |

Искәрмә. “ТГК-16” ЯАҖ җылылык чыганакларыннан пар һәм су рәвешендә бирелә торган 1 Гкал җылылык энергиясенә карата ягулык чыгымы зурлыклары:

| Т. № | Көйләнүче оешманың атамасы | Ел | Су | Алынган парның басымы | | | | Үткен һәм редукция-ләнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2-2,5 кг/см$^2$ | 2,5-7,0 кг/см$^2$ | 7,0-13,0 кг/см$^2$ | > 13,0 кг/см$^2$ | |
| 1 | “ТГК-16” | | | | | | | |
| 1.1 | Чыганак – “ТГК-16” филиалы – Казан ТЭЦы-3 | 01.01.2015-30.06.2015 | 401,64 | | | 518,12 | 582,38 | 642,43 |
| | | 01.07.2015-31.12.2015 | 438,53 | | | 565,71 | 635,87 | 701,65 |
| 1.2 | Чыганак – “ТГК-16” филиалы – Түбән Кама ТЭЦы (ПТК-1) | 01.01.2015-30.06.2015 | 350,49 | | | | 508,22 | 560,79 |
| | | 01.07.2015-31.12.2015 | 365,00 | | | | 529,26 | 584,01 |

Татарстан Республикасытарифларбуенча
Дәүләт комитеты, Тарифларбуенчакарарларны
кабул итү, оештурыһәмҗайга салу бүлеге